КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 24 октябрь г.Казань № 947

Татарстан Республикасының Ситуацион үзәкләре реестрын алып бару тәртибен раслу турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органында, федераль башкарма хакимият органының Татарстан Республикасы буенча территориаль органында, Татарстан Республикасы муниципаль районы һәм шәһәр округы җирле үзидарә органында, оешмада эшләгән һәм Татарстан Республикасының Бүленгән ситуацион үзәгенә керә торган ситуацион үзәкләрне функциональ, мәгълүмати-технологик, оештыру, норматив хокукый тәэмин итүгә үрнәк таләпләр стандартын һәм Бүленгән ситуацион үзәгенә керә торган ситуацион үзәкләрне аккредитацияләү турында нигезләмәне раслау турында» 2018 ел, 02 октябрь, 894 нче карарын үтәү өчен, шулай ук Татарстан Республикасының Ситуацион үзәкләре реестрын алып баруны оештыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Татарстан Республикасының Ситуацион үзәкләре реестрын алып бару тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына, шулай ук федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарына, Татарстан Республикасы муниципаль районы һәм шәһәр округы җирле үзидарә органнарына, оешмаларга Татарстан Республикасының Бүленгән ситуацион үзәгенә керә торган ситуацион үзәкләр эшчәнлеген оештырганда әлеге әлеге карар нигезендә эш итәргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Мобилизацион әзерлек һәм махсус программалар идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 24 октябрь, 947 нче
карары белән расланды

**Татарстан Республикасының Ситуацион үзәкләре реестрын алып бару тәртибе**

1. Гомуми нигезләмәләр

Татарстан Республикасының Ситуацион үзәкләре реестры (алга таба – Реестр) – Татарстан Республикасы территориясендә эшли торган, аларны исәпкә алу һәм бердәм мәгълүмат киңлеген оештыру максатларында формалаша торган бердәм багланышлар регламенты буенча эшли торган ситуацион үзәкләр исемлеге.

Реестрны формалаштыру һәм алып баруның төп бурычы булып Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органында, федераль башкарма хакимият органының Татарстан Республикасы буенча территориаль органында, Татарстан Республикасы муниципаль районы һәм шәһәр округы җирле үзидарә органында, оешмада эшләгән һәм Татарстан Республикасының Бүленгән ситуацион үзәгенә керә торган ситуацион үзәкләрнең бердәм базасын төзү тора.

Реестр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 18 октябрь, 2750-б номерлы боерыгы белән вәкаләтләр бирелгән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының структур бүлекчәсе (алга таба – Координатор) тарафыннан алып барыла.

Татарстан Республикасының Ситуацион үзәкләре реестрын алып бару тәртибе (алга таба – Тәртип) мәгълүмат составын һәм аны Реестрга кертү кагыйдәләрен, Реестрны алып баруга таләпләрне билгели.

2. Мәгълүматны Реестрга кертү кагыйдәләре

2.1. Ситуацион үзәк паспортыннан мәгълүмат, шулай ук ситуацион үзәкне аккредитацияләү нәтиҗәләре буенча мәгълүматлар Реестрга кертелергә тиеш.

2.2. Ситуацион үзәкләр эшли торган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Татарстан Республикасы муниципаль районы һәм шәһәр округы җирле үзидарә органнары, оешмалар (алга атаба – оешмалар) тарафыннан ситуацион үзәкне Реестрга кертү өчен ситуацион үзәк паспорты эшләнә.

Ситуацион үзәк паспортын тутыру формасы һәм тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 02 октябрь, 894 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органында, федераль башкарма хакимият органының Татарстан Республикасы буенча территориаль органында, Татарстан Республикасы муниципаль районы һәм шәһәр округы җирле үзидарә органында, оешмада эшләгән һәм Татарстан

Республикасының Бүленгән ситуацион үзәгенә керә торган ситуацион үзәкләрне функциональ, мәгълүмати-технологик, оештыру, норматив хокукый тәэмин итүгә үрнәк таләпләр стандартына (алга таба – Стандарт) 1 нче кушымтада китерелгән.

Ситуацион үзәк паспортын эшләп бетергәннән соң оешма аны Татарстан Республикасының бердәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасы (алга таба – БВЭДС) ярдәмендә җитәкче имзасы белән ситуацион үзәкне теркәү турында хат белән бергә Координаторга җибәрә. Оешманың БВЭДС булмаган очракта ситуацион үзәк паспортын кәгазьдәге озату хаты белән тапшыру рөхсәт ителә.

Оешма җитәкчесе Координаторга бирелә торган мәгълүматларның тулылыгы һәм дөреслеге өчен җавап тота.

Координатор оешманың мөрәҗәгатен тапшырылган паспортның Стандарт таләпләренә туры килүен мөрәҗәгать кергән көннән соң өч эш көне эчендә оешманың мөрәҗәгатен карап тикшерә. Паспорттагы мәгълүмат тулы булмаган очракта Координатор күрсәтелгән вакытта җитмәгән мәгълүматны оешмадан соратып ала. Оешма язмача сорату кергән көннән соң 10 эш көненнән артмаган вакыт эчендә Координаторга соратылган мәгълүматны бирә.

Соратылган мәгълүмат югарыда күрсәтелгән вакытта бирелмәгән очракта Координатор ситуацион үзәкне Реестрга кертүдән оешмага баш тартырга хокуклы, өч эш көне эчендә язма формада мотивлаштырылган җавап биреп.

Оешма тапшырган ситуацион үзәк паспортын карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Координатор ситуацион үзәкне Реестрга кертү турында яки кертүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Оешманың ситуацион үзәген Реестрга кертү турында карар кабул ителгәндә Координатор ситуацион үзәккә код бирә, ул ситуацион үзәкнең паспортында күрсәтелә һәм Реестрда теркәлә. Ситуацион үзәк кодының структурасы әлеге Тәртипкә кушымтада китерелгән. Оешманың ситуацион үзәген Реестрда теркәүне раслау Стандартка 2 нче кушымтада китерелгән форма буенча аңардан өземтә белән теркәлә.

2.3. Ситуацион үзәкне Реестрда теркәү тәмамланганнан соң оешма бер ай эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 18 октябрь, 2750-б номерлы боерыгы белән вәкаләтләр бирелгән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының структур бүлекчәсенә, ситуацион үзәкне төзү һәм аның эшчәнлеген регламентлаштыру документларын теркәп, ситуацион үзәккә аккредитация үткәрүгә сорату җибәрә.

Аккредитация нәтиҗәләре буенча Координатор өч эш көне эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органында, федераль башкарма хакимият органының Татарстан Республикасы буенча территориаль органында, Татарстан Республикасы муниципаль районы һәм шәһәр округы җирле үзидарә органында, оешмада эшләгән һәм Татарстан Республикасының Бүленгән ситуацион үзәгенә керә торган ситуацион үзәкләрне функциональ, мәгълүмати-технологик, оештыру, норматив хокукый тәэмин итүгә үрнәк таләпләр стандартын һәм Бүленгән ситуацион үзәгенә керә торган ситуацион үзәкләрне аккредитацияләү турында нигезләмәне раслау турында» 2018 ел, 02 октябрь, 894 нче карары белән расланган Татарстан

Республикасының Бүленгән ситуацион үзәгенә керә торган ситуацион үзәкләрне аккредитацияләү турында нигезләмә нигезендә Реестрга түбәндәге характердагы мәгълүматны кертә:

ситуацион үзәк Стандарт таләпләренә туры килгәндә – туры килү аттестатын бирү датасы, теркәү саны һәм аның гамәлдә булу вакыты;

аккредитацияләнүче ситуацион үзәк билгеләнгән таләпләргә туры килмәгәндә һәм аттестация комиссиясе билгеләгән кимчелекләрне тиз арада бетерү мөмкин булмаганда – туры килү аттестатын бирүдән баш тарту яки элек бирелгән аттестатның гамәлен туктатып тору турында тамга.

Ситуацион үзәкне Реестрдан чыгару өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

оешманың эшчәнлеге туктатылу яки бетерелү;

Реестрга керткәндә алдан ук дөрес булмаган мәгълүмат бирү.

## 3. Реестрны алып баруга һәм аңардагы мәгълүматны бирүгә таләпләр

Реестрны алып бару мәгълүмат саклау буенча Россия Федерациясе законнары таләпләрен саклап, электрон формада гамәлгә ашырыла.

Ситуацион үзәк паспотына чагылыш тапкан реквизитлар, технологияләр, кулланыла торган мәгълүмат ресурслары һәм аларга керү алымнары турында белешмәләр үзгәргән очракта оешма бу хакта өч эш көне эчендә Координаторга хәбәр итәргә тиеш. Әлеге мәгълүматны алганна соң Координатор кергән үзгәрешләрне өч эш көне эчендә Реестрга кертә.

Реестрдагы мәгълүматны бирү Кординатор адресына БВЭДС ярдәмендә яисә кәгазьдәге хат белән сорату җибәргәндә гамәлгә ашырыла.

Сорату алгач Координатор 10 эш көне эчендә гариза бирүчегә, соратыла торган мәгълүматны теркәп, җавап җибәрә.

Татарстан Республикасының ситуацион үзәкләре реестрын алып бару тәртибенә кушымта

## Ситуацион үзәк коды структурасы

XX.XX.XX.

Россия Федерациясе субъекты коды

ситуацион үзәк  үзәк эшли торган оешма коды
(1 – Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте
 башкарма органы;
2 – Татарстан Республикасы муниципаль районы
һәм шәһәр округы җирле үзидарә органы;
3 – федераль башкарма хакимият органының
Татарстан Республикасы буенча территориаль органы;
4 – оешма)

Татарстан Республикасының ситуацион үзәкләре
реестрында ситуацион үзәкнең тәртип саны

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органының коды 1 таблица нигезендә билгеләнә.

1 таблица

| Код | Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы исеме |
|---|---|
| 01. | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы |
| 02. | Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы |
| 03. | Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы |
| 04. | Татарстан Республикасы Мәдният министрлыгы |
| 05. | Татарстан Урман хуҗалыгы министрлыгы |
| 06. | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы |
| 07. | Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы |
| 08. | Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре буенча министрлыгы |
| 09. | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы |
| 10. | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы |
| 11. | Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы |
| 12. | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы |
| 13. | Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы |
| 14. | Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы |

| Код | Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы исеме |
| --- | --- |
| 15. | Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы |
| 16. | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы |
| 17. | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы |
| 18. | Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы |
| 19. | Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты |
| 20. | Татарстан Республикасының Биология ресурслары буенча дәүләт комитеты |
| 21. | Татарстан Республикасының Сатып-алулар буенча дәүләт комитеты |
| 22. | Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты |
| 23. | Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты |
| 24. | Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау буенча дәүләт комитеты |
| 25. | Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг буенча дәүләт комитеты |
| 26. | Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы |
| 27. | Республика «Татмедиа» басма һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы |
| 28. | Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе |
| 29. | Татарстан Республикасының Этил спитрын, алкоголь продукциясен җитештерү, аларның әйләнешен һәм сыйфатын дәүләт контролендә тотуны тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау дәүләт инспекциясе |
| 30. | Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе |
| 31. | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе |
| 32. | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Граждан хәле актларын теркәү идарәсе |
| 33. | Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналары һәм башка төр техникасы торышын тикшерүдә тоту идарәсе |

Татарстан Республикасы муниципаль районы һәм шәһәр округы җирле үзидарә органы коды кабул ителгән Татарстан Республикасын административ-территориаль бүлү нигезендә билгеләнә (2 таблица).

2 таблица

| Код | Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге исемлеге |
| --- | --- |
| 01. | Әгерҗе муниципаль районы |
| 02. | Азнакай муниципаль районы |
| 03. | Аксубай муниципаль районы |
| 04. | Актаныш муниципаль районы |
| 05. | Алексеевск муниципаль районы |
| 06. | Әлки муниципаль районы |
| 07. | Әлмәт муниципаль районы |
| 08. | Апас муниципаль районы |
| 09. | Арча муниципаль районы |
| 10. | Әтнә муниципаль районы |
| 11. | Баулы муниципаль районы |
| 12. | Балтач муниципаль районы |

| Код | Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге исемлеге |
|---|---|
| 13. | Бөгелмә муниципаль районы |
| 14. | Буа муниципаль районы |
| 15. | Югары Ослан муниципаль районы |
| 16. | Биектау муниципаль районы |
| 17. | Чүпрәле муниципаль районы |
| 18. | Алабуга муниципаль районы |
| 19. | Зәй муниципаль районы |
| 20. | Зеленодольск муниципаль районы |
| 21. | Кайбыч муниципаль районы |
| 22. | Кама Тамагы муниципаль районы |
| 23. | Кукмара муниципаль районы |
| 24. | Лаеш муниципаль районы |
| 25. | Лениногорск муниципаль районы |
| 26. | Мамадыш муниципаль районы |
| 27. | Менделеевск муниципаль районы он |
| 28. | Минзәлә муниципаль районы |
| 29. | Мөслим муниципаль районы |
| 30. | Түбән Кама муниципаль районы |
| 31. | Яңа Чишмә муниципаль районы |
| 32. | Нурлат муниципаль районы |
| 33. | Питрәч муниципаль районы |
| 34. | Балык Бистәсе муниципаль районы |
| 35. | Саба муниципаль районы |
| 36. | Сарман муниципаль районы |
| 37. | Спас муниципаль районы |
| 38. | Тәтеш муниципаль районы |
| 39. | Тукай муниципаль районы |
| 40. | Теләче муниципаль районы |
| 41. | Чирмешән муниципаль районы |
| 42. | Чистай муниципаль районы |
| 43. | Ютазы муниципаль районы |
| 44. | Казан ш. |
| 45. | Чаллы ш. |

Федераль башкарма хакимият органының Татарстан Республикасы буенча территориаль органының һәм бүтән оешманың ситуацион үзәгенә код бирү алардан мөрәҗәгатьләр керү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 18 октябрь, 2750-б номерлы боерыгы белән вәкаләтләр бирелгән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының структур бүлекчәсе кабул иткән ситуацион үзәкне Татарстан Республикасының ситуацион үзәкләре реестрына кертү турында карар буенча хронологик тәртиптә гамәлгә ашырыла.

______________________________